СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 13-22 от « 28 » июня 2023 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль хокукый актлар системасын актуальләштерү максатларында, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 январендәге №1-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы «Мамадыш муниципаль районы» Уставы нигезендә Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Мамадыш муниципаль районы Советының 2014 елның 18 ноябрендәге №11-34 карары белән расланган Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Мамадыш муниципаль районы рәсми сайты бүлекләрен урнаштыру һәм тотыру таләбенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Таләпләрнең 2 бүлегендәге 1 пунктының 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы коррупциягә каршы көрәш буенча»;

1.2. Таләпләрнең 2 бүлегендәге 1 пунктының 15 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты указларын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе указларын» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. Таләпләрнең 2 бүлегенең 1.1. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы коррупциягә каршы көрәш советы» гиперссылкасы буенча күчкәндә Татарстан Республикасы Рәисенең рәсми сайтының тиешле бүлекчәсенә керү гамәлгә ашырыла.»

1.4. Таләпләрнең 2 бүлегенең пункте 1.14 «Татарстан Республикасы Президенты указы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе указы» сүзләренә алмаштырырга»;

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2022 елның 27 июнендәге 8-14 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

000055

2.1. Нигезләмәнең 12 пунктындагы 7 пунктчасында «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Интернет-телекоммуникация челтәрендә Мамадыш муниципаль районы http://mamadysh.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Мамадыш муниципаль районы Советының регламент, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе А.П.Иванов